СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

20.12.2023 — с. Майдан — № 39-211

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне юкка чыгару хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019нчы елның 16нчы декабреннән 432-ФЗ Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының 25.09.2017 елгы 30-134 номерлы карары белән расланган нигезләмәне кире кагарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы — В.В.Михеев